МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2015 г.Казань № 286/2-пр

**Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2015 елның 24 июнендәге 624 номерлы карарын үтәү йозеннән

**б о е р ы к  б и р ә м:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Сөт терлекчелек комплексларын (сот фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер олешен каплауга субсидияләрне 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү тәртибен 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Сот терлекчелек комплексларын (сот фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау очен авыл хуҗалыгы төварларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына субсидияләр бирү турында килешүне 2 нче кушымта нигезендә;

1.3. Сот терлекчелек көмплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмәләре формасын 3 нче кушымта нигезендә.

2. Тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучыларга, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең һәм Россия оешмаларының җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләргә.

3. Бюджет алучы тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеген тикшерүне һәм раслауны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләргә.

4. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы С.М. Нигъмәтҗановка, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы И.Ш. Гафуровка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән һәм Россия оешмаларыннан федераль бюджеттан

субсидияләр алу өчен тапшырыла торган документларын кабул итүне тәэмин итәргә.

5. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының финанслау бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка әлеге Боерыкны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны 2015 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган күләмдә тәэмин итәргә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 16 декабрендәге 286/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш (алга таба – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр) һәм Россия оешмаларына субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында бирелә. Субсидияләр бирү максатын милек хокукында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына караган сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү тәшкил итә.

3. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне һәм Россия оешмаларын сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

4.1. Предприятиенең төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, сөт бирә торган мөгезле эре терлек үрчетү;

4.2. Сөт терлекчелек комплексын (сөт фермасын) төзү өчен каралган объектның куәте – милек хокукында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына караган 400 һәм аннан күбрәк баш сыер (башмак) һәм (яки) 100 һәм аннан күбрәк ана баш кәҗә;

4.3. Сөт терлекчелек комплексын (сөт фермасын) модернизацияләү өчен каралган объектның куәте – милек хокукында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына караган 200 һәм аннан күбрәк баш сыер (башмак) һәм (яки) 100 һәм аннан күбрәк ана баш кәҗә;

4.4. Объектның проектта каралган куәтенең 100 проценты күләмендә җылылык, энергетика һәм су ресурслары белән тәэмин ителгән булуы, ул башлангыч рөхсәт бирү документациясе һәм тоташуның техник шартлары белән расланган булырга тиеш;

4.5. Терлекчелек комплексын (сот фермасын) модернизацияләү, юнәлеш кысаларына туры килә торган барлык шартлар үтәлгән очракта, түбәндәге бер яки ике юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла:

а) сөт саклау, саву, кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү системаларын җайланмаларын модернизацияләү:

- саву җайланмаларын җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

- сөт продукциясен суытып эшкәртү һәм саклауны да кертеп, сөт кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү җайланмаларын җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

- яңа саклау технологияләренә җайлаштырып бинаның планировкасын үзгәртү.

б) азык җитештерү һәм тирес чыгару өчен каралган җайланманы модернизацияләү:

- азык әзерләү һәм терлеккә бирү өчен каралган җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

- тирес чыгару өчен каралган җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру.

5. Субсидияләр бетү стадиясенә күчкән яки бөлгенлекка (банкротлыкка) чыккан дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына бирелми.

6. Субсидия бирелә торган елга кадәрге елның 1 гыйнварына кадәр төзелә һәм (яки) модернизацияләнә башлаган сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр, өстәмә бәягә салымны исәпләмәгәндә, смета бәясенең һәм проект-тикшеренү эшләренә киткән чыгымнарның 20 процентыннан чыгып бирелә, әмма ул сумма объектның иң югары бәясеннән югарырак була алмый.

Объектның иң югары бәясе объект куәтенең бер берәмлеге бәясенең Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган чик зурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Турыдан-туры чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү актын тапшырганнан соң башкарыла.

7. Әлеге тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм Россия оешмалары Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма исәп-хисап сметасының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәсен;

төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсенең күчермәсен;

проект документациясенә һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасына уңай бәяләмәнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәсен;

объектны төзүгә рөхсәтнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәсен;

төзүгә һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәләренең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәсен;

“Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” КС-2 номерлы статистика формасы буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәләрен;

“Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә” КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәләрен;

эшләрне хуҗалык эшләре ысулы белән башкарганда “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” КС-2 номерлы статистика формасы һәм “Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә” КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы раслаган күчермәләрен;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган банк, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәләрен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

8. Министрлык:

субсидияләр бирү соралган гаризаны кергән көнендә үк журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа мөһер сугыла;

гариза теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм Россия оешмалары белән Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү төзи.

10. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган субсидияләр бирү өчен җыелма исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган хосусый счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең һәм Россия оешмаларының исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң ике көн эчендә күчерә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларның тулы булмаган комплекты тапшырылу яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

клган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

11. Алынган субсидияләр, аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет керменә кире кайтарылырга тиеш.

12. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керменә субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

13. Әлеге Тәртипнең 11 һәм 12 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет кеременә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

14. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

15. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче һәм Россия оешмасы тарафыннан Министрлыкка тапшырылган документларның дөреслеге очен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

16. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 16 декабрендәге
286/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына субсидияләр бирү турында

**КИЛЕШҮ №_____**

Казан ш. «____»____________2015

Бер яктан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы исеменнән, алга таба "Министрлык" дип аталачак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре" 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып эшли торган Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Әхмәтов Марат Готыф улы һәм икенче яктан

_______________________________________________________________

(субсидияләр алучыларның исемнәре, ИНН)

исеменнән, алга таба "Субсидия алучы" дип аталачак, ____________________ нигезендә эшли торган

_______________________________________________________________,

(Ф.И.А.и.)

барысы бергә "Яклар" дип йөртеләчәк, Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү тәртибе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Министрлык әлеге Килешү һәм Министрлык боерыгы белән расланган Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү тәртибе нигезендә 400 һәм аннан күбрәк баш сыер (башмак) һәм (яки) 100 һәм аннан күбрәк ана баш кәҗә исәпләнгән сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә, 200 һәм аннан күбрәк баш сыер

(башмак) һәм (яки) 100 һәм аннан күбрәк ана баш кәҗә исәпләнгән сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) модернизаңияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирергә йөкләмә ала.

1.2. Субсидия алучыга субсидияләр терлекчелек биналарының Субсидия алучының милкендә булган очракта бирелә.

1.3. Субсидияләр бирү “2015 елга , 2016 һәм 2017 еллар план чорына федераль бюджет турында” 2014 елның 1 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законда каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Министрлыкка расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чигендә башкарыла.

1.4. Субсидияләр бирү максатлары сөт җитештерү күләмнәрен арттыруны тәэмин итә торган икътисадый һәм технологик шартлар тудырудан гыйбарәт.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. **Министрлык түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:**

2.1.1. Субсидия алучыларга субсидияләрне, сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне 2015 елда законнарда билгеләнгән федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү шартларын һәм Тәртибен үтәп, билгеләнгән лимитлар чигендә үз вакытында күчерергә.

2.1.2. Әлеге Килешүнең һәм Тәртипнең нигезләмәләрендә каралган бурычлар үтәлмәгән очракта субсидияләр күчерүне туктатып торырга яки аларның күләмен киметергә.

2.1.3. Субсидияләр алучыларның субсидияләр алу өчен кирәкле документларын тикшерергә.

2.1.4. Субсидия алучыга Субсидия алучының Килешүдә каралган йөкләмәләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр бирергә.

2.1.5. Субсидияләр биргән вакытта куелган шартлар Субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, алынган субсидияләрне кире кайтаруны таләп итәргә.

2.2. **Субсидия алучы түбәндәгеләрие үтәргә тиеш:**

2.2.1. Министрлыкка Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизаңияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән бирү тәртибендә билгеләнгән субсидияләрне алу өчен кирәкле документларның тиешенчә рәсмиләштерелгән пакетын тапшырырга.

2.2.2. Сөт терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) куәтләрен файдалануга кертү буенча субсидия бирүне проект-смета документларында расланган нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә.

2.2.3. Иң күбе өч эш көненә тигез срокта язма рәвештә Министрлыкка түбәндәгеләр турында хәбәр итәргә:

- карар кабул ителгән көннән алып бетерелү яки үзгәртеп төзелү турында;

- арбитраж суд тарафыннан билгеләмә чыгарылган көннән башлап “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган банкротлык турындагы эштә күрелә торган процедураларны башлау турында;

- карар кабул ителгән көннән соң адрес (урнашу урыны) үзгәрү турында.

2.2.4. Алынган субсидияләрне аларны бирүнең Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булу буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет керемenә кире кайтарырга.

2.2.5. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрне хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемenә кире кайтарырга.

2.2.6. Министрлыкка һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарына аларның субсидияләр алучының субсидияләр бирү шартлары, максатлары үтәлешен тикшерүенә ризалык бирергә.

**2.3 Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.3.1. Субсидия алучыдан әлеге Килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат, белешмәләр һәм документлар соратып алырга.

2.3.2. Субсидия бирү шартларының, максатларының һәм аларны бирү тәртибенең Субсидия алучы тарафыннан үтәлү-үтәлмәвен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерергә.

**2.4. Субсидия алучы түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.4.1. Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәмен алырга. Субсидияләр законнарда билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары бирелә.

2.4.2. Консультация һәм мәгълүмат алу ярдәменә.

## 3. СУММАЛАРНЫ КИРЕ КАЙТАРУ ТӘРТИБЕ

3.1. Башкарма хакимият органы яки башка вәкаләтле тикшерү һәм күзәтчелек органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрелеп, субсидияләр бирүнең тиешле тәртибендә (кагыйдәләрендә) һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән максатларның һәм шартларның бозылу очраклары ачыкланса һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләрнең һәм документларның тапшырылуы билгеле булса, бирелгән субсидияләрне Субсидия алучы Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет керемenә кире кайтарырга тиеш.

3.2. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет керемenә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

## 4. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ

4.1. Килешүнең Яклары Килешү буенча барлыкка килә торган бәхәсләрне һәм аңлашылмаучанлыкларны Яклар арасында сөйләшүләр үткәреп хәл итү өчен барлык чараларны да күрәләр.

4.2. Килешүнең Яклары арасында Килешү буенча барлыкка килә торган барлык бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар, әгәр алар сөйләшүләр үткәреп хәл ителмәсә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

## 5. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

5.1. Яклар әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү шартлары нигезендә җавап тоталар.

5.2. Субсидия алучы Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылыуы һәм Килешүдә билгеләнгән шартларның үтәлеше өчен җаваплы була.

5.3. Субсидия алучы, шартларны үтәмәгән очракта, бирелгән субсидияләрне әлеге очракның билгеле булу датасыннан һәм Министрлыкның тиешле таләбен алган датадан алтмыш көн эчендә федераль бюджет керемenә кире кайтарырга тиеш.

## 6. БАШКА ШАРТЛАР

6.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр, өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә башкарылган һәм ике Якның да моңа вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган булсалар, дөрес булалар һәм аның аерылгысыз өлешләре булып торалар.

6.2. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, алар бертигез юридик көчкә ия.

6.3. Әлеге Килешү ике Якның да кул куярга вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган вакыттан алып 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## 7. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ ТҮЛӘҮ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| Министрлык: | Субсидия алучы: |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы<br>һәм азык-төлек министрлыгы<br>420014, Татарстан Республикасы,<br>Казан ш., Федосеевская ур., 36 нчы й.<br>р/с 40201810900000000002<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ<br>БАНКЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘРЕ БҮЛЕГЕ<br>Татарстан Республикасы буенча УФК<br>(Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы<br>һәм азык-төлек министрлыгы, 03112001090)<br>ИНН 1654019555<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1021602854580 | |
| Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры<br>урынбасары – Авыл хуҗалыгы<br>һәм азык-төлек министры<br>______________________М.Г. Әхмәтов | Җитәкче<br>________________Ф.И.А.и. |

2015 елның 16 декабрендәге 286/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

Форма

## Сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Россия оешмаларына федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмәләре

________________________________________________________________
(субсидия алучының исеме)

| Объектның, торак пунктның, муниципаль районның исеме | НДС исәпләмәгәндә, объектның һәм проект-тикшеренү эшләренә киткән чыгымнарның смета бәясе, сум | Субсидия ставкасы | Ссубсидияләр суммасы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| сөт терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә | | НДС исәпләмәгәндә, объектның смета бәясеннән һәм проект-тикшеренү эшләренә киткән чыгымнарның 20% | |
| Барлыгы: | | Х | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе ____________ (имза) ____________ ФИАи

Баш бухгалтер
(мөһер булган очракта) ____________ (имза) ____________ ФИАи

Татарстан Республикасы ____________
районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы ____________ (имза) ____________ ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районында
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ____________ (имза) ____________ ФИАи

Баш бухгалтер
(мөһер) ____________ (имза) ____________ ФИАи

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
(мөһер) ____________ (имза) М.Г.Әхмәтов